**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**22.05.2023** **№ 619**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын төзү турында» 2019 елның 31 июлендәге 1197 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау районы Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын төзү турында» 2019 елның 31 июлендәге 1197 номерлы карарына (20.04.2021 № 392, 31.03.2023 № 414 белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1322 номерлы сайлау участогын (сайлаучылар саны 163 кеше) бетереп, һәм аның территориясен 1299 номерлы сайлау участогы (сайлаучылар саны - 2207 кеше) территориясе белән берләштереп, чикләренә түбәндәгеләр: Бөреле җәнлек совхозы поселогы, Бөреле т.юл. разъезды поселогы, Пимәр авылы, Сосновка авылы, Керосиново, Кирилловка авыллары, «Тимошкино» ДНТ кергән, Бөреле җәнлек совхозы поселогы, Кольцевая ур., 33й, Мәдәният сарае бинасы адресы буенча бердәм 1299 номерлы сайлау участогы төзеп, сайлау участоклары чикләренә төгәлләштерү үткәрергә.

Телефон: (884365) 3-29-24. Сайлаучылар саны – 2370;

2) 1288 номерлы участок сайлау комиссиясенең (алга таба - УИК) тавыш бирү бинасын Әлдермеш авылы, Ленин ур., 26 й. адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасыннан «Әлдермеш урта мәктәбе» МБОУ бинасындагы тавыш бирү өчен яраклы бүлмәгә түбәндәге адрес буенча күчерергә: Әлдермеш авылы, Хәбибуллин ур., 18 й;

3) 1316 номерлы УИК тавыш бирү урыны адресын, аны түбәндәге

редакциядә бәян итеп, төгәллек кертергә: Пановка авылы, Крупская урамы, 34 йорт, Сәнгать мәктәбе бинасы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча, шулай ук «Биектау хәбәрләре» район газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Биектау муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Хәкимуллин